Мәкаләдә хәзерге милли прозаны жанрлык хасиятләре, әдәби алымнар байлыгы яссылыгында бәяләү омтылышы ясала. Әлеге сыйфатлар ачык гәүдәләнгән язучыларның әдәби әсәрләре аның тикшерү объекты булып тора. Күзәтүләргә нигезләнеп, соңгы еллар татар прозасы үсешендәге аерым тенденцияләр ачыклана. Бүгенге татар прозасын өйрәнгәндә, хикәя яңарыш һәм үсеш кичерүче, традицион алымнардан психологизм, фәлсәфи гомумиләштерүләр, эмоциональлек, символларны үз иткән жанр буларак билгеләнә. Соңгы елларда дөнья күргән күп кенә хикәяләрдә иҗтимагый мәсьәләләрнең шәхес, кеше фәлсәфи проблемалары белән үрелеп тасвирлануы ассызыклана. А. Әхмәтгалиева хикәяләре укучы игътибарын милли, шәркый мәдәният традицияләренең дәвам иттерелүе, шигъриләшә бара торган эпик теле белән җәлеп итә. Әдәби алымнарны төрләндерү ярдәмендә экзистенциаль мотивларны калку гәүдәләндергән әсәрләрдән Р. Галиуллин, Г. Әдһәм, Р. Рахман, И. Иксанова, Л. Ибраһимова һ. б. хикәяләре аерылып тора. Авангард прозага мөнәсәбәтле кече эпик жанрлардан М. Кәбиров, З. Хөсникяр, Л. Әбударова әсәрләре игътибарга лаек. Повесть жанры сатирик текст поэтикасын үстерү ягыннан кызыклы (З. Хәким, Р. Батулла, Ф. Баттал, Р. Рахман һ. б.). Соңгы елларда экзистенциаль сагыш мотивын туган нигезгә әйләнеп кайту, милли-әхлакый кыйммәтләрне тергезү эчтәлегенә үреп тасвирлаган әсәрләр еш кына бәян жанры кебек тәкъдим ителә (А. Әхмәтгалиева, Н. Гыйматдинова һ. б. бәяннәре). XXI гасыр башы татар әдәбиятында иң зур үзгәрешләр кичергән жанрлардан романның үзенчәлекле үсеше күзәтелә. Хәзерге татар прозасында З. Хәким, З. Хөсникяр, Ф. Бәйрәмова, В.Имамов романнарының башка күләмле эпик текстлардан тема яңалыгы, сюжет структурасы һәм әдәби алымнар байлыгы ягыннан аерылып торуы ассызыклана.

Тәкъдим ителә торган темага мөнәсәбәтле хәзерге татар прозасын иҗат юнәлешләре, стиль тенденцияләре яссылыгында өйрәнгән Д.Заһидуллина, әсәрләрне шәрехләү барышында әдәби барыштагы аерым күренешләрне билгеләп куйган М. Хәбетдинова, Л. Дәүләтшина, А. Шәмсутова һ. б. хезмәтләре игътибарга лаек.

**Төп төшенчәләр:** хәзерге татар прозасы, хикәя, повесть, бәян, роман, экзистенциаль мотивлар, психологизм, символлар.

Татар сүз сәнгатен концептуаль якын килеп өйрәнгән әдәбият галиме Д. Заһидуллина фикеренчә, «хәзерге татар прозасының үсешен, беренче, нәүбәттә иҗтимагый-сәяси барыш билгели, бу үз чиратында әдәбиятның җәмгыятьтәге вазифасы һәм урыны үзгәрүгә китерә» (тәрҗ. безнеке. – *Г. Г.*) [Загидуллина, б. 234]. Соңгы ике дистә елда татар прозасында, реалистик һәм романтик юнәлешкә мөнәсәбәтле әдәби текстлар белән беррәттән, постмодернистик проза, метафизик реализм, постколониаль мотивлар, интеллектуаль тенденция урын ала [Загидуллина].

Милли әдәбият гыйлемендә әдәби текстларны, жанрлык хасиятләре ягыннан даими өйрәнеп, сюжет корылышы, идея-эстетик камиллек яссылыгында бәяләп-шәрехләп бару әһәмияткә ия. Хәзерге татар прозасын бу ноктадан тикшергәндә, шунысы аерымачык күзгә ташлана: һәрвакыттагыча, «хикәя

үзгәрешләргә иң сизгер жанр булып кала» [Заһидуллина, б. 234]. Әдәби алымнарны төрләндергән һәм баеткан бүгенге әдипләр арасында М. Кәбиров, З. Хөснияр, А. Әхмәтгалиева, Р. Галиуллин, Р. Рахман, З. Хәким, И. Иксанова, Л. Әбударова, Л. Ибраһимова, Г. Әдһәм һ. б. хикәяләре аерылып тора. Язучылар татар хикәясендә традицион булган алымнардан психологизм, фәлсәфи гомумиләштерүләр, эмоциональлек, символлар теле белән эшләүне бүген дә үз итә, шул ук вакытта авангард алымнарны да читкә какмый. Күп кенә хикәяләрдә иҗтимагый проблемалар шәхес, кеше фәлсәфәсе мәсьәләләре белән тыгыз үрелеп сурәтләнеш ала.

Яңарыш һәм үсеш кичергән заман хикәясендә татар әдәбияты өчен традицион алымнарның яңа мөмкинлекләре барлана. А. Әхмәтгалиева хикәяләре [Әхмәтгалиева] шул яссылыкта игътибарны үзенә тарта [Загидуллина, б. 127]. Аларда язучы авылның киләчәге, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр турында уйланулар аша яшәеш мәгънәсе хакында фикер белдерә. «Кайтаваз» әсәрендә моң образын кайма итеп урнаштыру, шартлы-метафорик сурәтләрне куллану, *сылу каеннар шавы, кызлар тавышы, челтерәгән инеш агышы* детальләрен хикәянең соңгы өлешендә *колакны иркәләгән моң, җил канатында тибрәлгән кайтаваз* дип кабатлау ярдәмендә ана горурлыгы турындагы фикер көчәйтелә. Әдәби детальләрдән *өй исе,өй төсе* ике яры болытларда кушылган елга образы белән янәшә куела, шул рәвешле, кешеләр арасындагы якты, ихлас мөнәсәбәтләргә нигезләнгән яшәеш тәртибе турындагы фикер үткәрелә. Буыннар кайтавазы – елга-вакытның ике яры ул, вакытларны бары үзара якты мөнәсәбәтләр генә тоташтырып тора ала дигән фикер җиткерелә. «Коткаручы» хикәясендә дә әдәби алымнарны төрләндерү ярдәмендә авторның тормыш асылы, яшәү мәгънәсе турындагы фәлсәфи карашы ассызыклана. Аның башлам өлешендәге *яз исе* детале бетем өлешендәге *тау бөтнеге, җиләк яфрагы исе* детальләре белән кайма хасил итә. Ибраһим-Рәйханә, Мансур тарихлары үлем экзистенциаль чигенә аяк атлаган кешене яшәү ягына чыгарып булган кебек, бетүгә йөз тоткан авыл-җәмгыятьне, кешелекне дә коткару мөмкин дигән фикерне алга чыгара.

А. Әхмәтгалиеваның «Тау итәгендә» хикәясендә моңарчы карьера баскычы, властька үрмәләү турында уйламаган гади укытучы – җир кешесенең авыл башлыгы итеп билгеләнү мөмкинлеге алдыннан булган кичерешләре эчке монолог алымы белән бәян ителә. Әсәрдәге төп фикерне аңларга *һавага чөелгән чалгы* детале ярдәм итә. Тау итәгендәге сары күзле ромашкалар, кыңгыраулар, кәрешкәләргә, мәмрәп пешкән җир җиләгенә, кырмыскалар оясына селтәнергә йөрәге җитмәгән ир, тиз арада җыелышка кайтырга кирәклеген ишетүгә, алыштырып куйгандай, чалгысын төшереп, нәзек билле чәчкәләргә селтәнгәнен сизми дә кала. Шул рәвешле, хисләр үзгәрә: «властька үрмәләү» омтылышы символик «тау итәгеннән югарыга ашыгу» дип ассызыклап куела [Әхмәтгалиева].

Гүзәл Әдһәмнең «Зәңгәр кашлы көмеш алка» [Әдһәм] хикәясендә көчле позициягә чыгарылган әдәби деталь үткән һәм бүгенге вакыт сызыгын – буыннарны тоташтыра. Айдарның Зәйтүнәгә карата хисләре үтә дә ихлас, әмма карьера хакына, ул алардан баш тартырга мәҗбүр. Якты хисләр истәлеге, буыннан буынга күчә торган матурлык – *алка*, еллар үткәч, Айдарны бер мәлгә үз асылына кайтара, хәтта ул кызы Нәзирәне тапканга сөенә дә кебек, ләкин, кәнәфинең тагын да югарырагы тәкъдим ителүгә, кызы турында мәгълүмат туплап биргән «Зәңгәр кашлы көмеш алка» операциясендә катнашканнарны юлыннан алып куя.

Сирень Якупованың «Туй алдыннан» [Якупова] хикәясендә лирик-эмоциональ дулкында гомернең гел туйлардан торуы, һәр чорның үз туе-бәйрәме булу турындагы фикер *күлмәк* детале ярдәмендә үстерелә. «Аты юкның...» хикәясендә Сабантуй мифологик мотивы, *ат* образының төрле вариацияләре кулланыла, «*ир-атсыз йорт*» «*ир-атсыз ил*» образы белән янәшә куелып, иҗтимагый проблематика калкытыла. «Әти моңы» [Якупова] хикәясендәге ятимлек, ата-тирәкне эзләү, моң мотивлары милли проблеманы белдерүгә хезмәт итә. Гөлинә Гыймадованың «Пәрәвез җебе яки кыз-әби кыйссасы» [Гыймадова] хикәясендә әхлакый бөтенлекнең вакыт сынавын үтүе, мәхәббәткә тугрылык турында фикер үткәрелә, төш алымы эчке халәтне әйтеп бирү вазифасын башкара.

Р. Галиуллин «Җиһан» [Галиуллин] хикәясендә ата кешенең көтеп алынган газиз кызын күмү фаҗигасен импрессионистик алымнар белән сөйләп бирә. Классик татар хикәясе буларак каралырга лаек бу әсәрне Д. Заһидуллина болай бәяли: «Әле генә кыз

баласын югалткан эти кеше, аның бабасы хәсрәтен автор, психологизм алымын кулланып, кабер казу вакыйгасында тергезә. Ялгышлардан тәүбәгә килү, иманга басу турында соңгы биш-ун елда шактый күп әсәрләр язылса да, төп фикернең ярдәмче рольдә, чишелеш булып килүе хикәяне үгет-нәсыйхәт яссылыгына төшүдән саклап кала алган» (тәрҗ. безнеке. – Г. Г.) [Загидуллина, б. 127–128].

Реалистик хикәяләр арасында Рифә Рахманның «Бәйрәм»е [Рахман, 2017] тетрәндергеч сюжеты, структур яктан камиллеге, проблема куелышы ягыннан игътибарга лаек. Әзербайҗан егетенә яратып кияүгә барган Гөлсарының язмышы туган нигезгә әйләнеп кайту тарихы кебек сурәтләнеш алган. Улын югалткач, ирен өйләндереп, аның бишенче баласына сөт әнисе булган Гөлсары фаҗигасендә «Гаяз Исхакыйлардан килгән корбанчыллык, сабырлык, зирәклек мотивлары калку яңгыраш ала» [Yusupov, Gilazov, б. 346]. И. Иксанованың «Балан чәчәге» җыентыгындагы [Иксанова] «Онытылган парад», «Сугыш корбаны» хикәяләре дә Бөек Ватан сугышы хакыйкатен, тылдагылар тормышын реалистик планда – ничек бар шулай чагылдыруы белән кызыклы.

Р. Габделхакованың 2004–2006 еллар аралыгында романтик пафос белән, кеше хисенең сафлыгын югары күтәреп язылган хикәяләрен бәяләп, Д. Заһидуллина болай ди: «Әдибәнең хикәя жанрында төп табышы – әсәр текстында, сюжетында берничә катламны берләштерү» (тәрҗ. безнеке. – *Г. Г.*) [Загидуллина, б. 121]. Язучының соңрак язылган «Фәрештәң булыр идем» әсәрендә, шифаханәдә авыру апасын назлап, иркәләп караган кызга бай егетнең гашыйк булуы романтик алымнар белән җиткерелә.

Шул рәвешле, традицион реалистик һәм романтик юнәлешләргә мөнәсәбәтле хикәяләрдә милли, шәркый мәдәният традицияләренең дәвам иттерелүе, Ә.Еникиләрдән килгән символлаштыру, шигъриләшә бара торган эпик тел, модернистик алымнарга мөрәҗәгать итү тенденцияләре күзәтелә.

М. Кәбиров, З. Хөснияр, З. Хәким, Л. Әбударова кебек әдипләр эшчәнлегендә авангард прозага мөнәсәбәтле хикәяләр күзәтелә. XXI гасыр башында милли хикәяне яңа юнәлешкә борган М. Кәбировның «Мин яратам сине» хикәясе [Кәбиров] постмодернистик тәҗрибәләренең чираттагысы булып тора. «Әсәр тулысы белән метафора» [Загидуллина, б. 177]: биредә автор фикере өстенлекле булудан туктап, дөнья хаос халәтендә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре, кыйммәтләр, юнәлеш тотар үзәкләре булмаган хәлдә тасвирлана. М. Кәбиров укучы белән урын-вакыт яссылыгында уен кора, симулякрлар ярдәмендә аң төпкелендәге процесслар беренче планга чыгарыла.

З.Хөсниярның «Кичү» хикәясе [Хөснияр, 2012] проблема куелышы һәм авангард алымнар кулланылышы ягыннан игътибарга лаек. Бу әсәрдә дә әдәби алымнарны төрләндерү ярдәмендә авторның тормыш-яшәеш турындагы фикерләре җиткерелә [Гайнуллина, б. 102]. Язучы шартлы-метафорик сурәтлелек, дулкын образын кайма итеп урнаштыру ярдәмендә яшәеш турындагы әрнү-сызлануларын сөйләп бирә. Фәлсәфи проблеманың Зур Суны кичү – тормышта олы бер сынауны – яшәү белән үлем чиген үтү дип куелышы экзистенциаль мотивны көчәйтә. Аксакал архетибына якын торган картның «нигез чакыра» дип әрнүе – авторның инрәп су астына киткән әхлакый кануннарны, ышану-иманны, ягъни буыннардан килгән өнне укучысына искәртү омтылышы кебек кабул ителә. З. Хөснияр, укучы хәтерендә яши торган дини-мәдәни мәгълүматлар белән ассоциация тудырып, иҗтимагый проблеманы калкытып куюга ирешә.

Дин фәлсәфәләре яңача яңгыраган әсәрләр арасында Л. Әбударованың «Газап» [Әбударова] хикәясендә З. Хәкимнәрдән килгән авангард проза традицияләре дәвам иттерелә. Әсәрдә авангард алымнар ярдәмендә яшәешкә булган караш, мөнәсәбәтләр янәшә куела. Азгын егет белән саф кыз арасындагы мәхәббәт тарихы кебек башланган тема үзгә борылыш ала. Кыз бала азгынлык юлына баса, егет, киресенчә, ярата башлагач, рухи чистарыну, сафлану кичерә. Музыкант егетнең үз асылына кайтуы – газап нәтиҗәсе, диелә, ләкин Нәфисәне исә газап азгынлык юлында тота. Яратуның газап икәнлеге турындагы сүзләр чиркәүдә әйтелә: «Мәчеттә башкача. Чиркәүдә син Аллаһ улы белән үзең генә каласың. Күзгә-күз. Иисус Христос һәм син. Ә мәчеттә Аллаһ синең йөрәгеңдә, ә син үз-үзең белән» [Әбударова, б. 60]. Автор диннәр фәлсәфәсен янәшә куйганда, аның чикләрен уза, яшәеш фәлсәфәсен ярату белән бәйләп, экзистенциаль яссылыкта теркәп куя. Автор аң агышы, автоматик язу алымнарын кулланып,

шизоанализга мөрәҗәгать итеп, укучының акыл эшчәнлеген активлаштыра.

Хәзерге прозада сатирик шартлылыкка мөрәҗәгать итеп язылган хикәяләр шәлкеме игътибарга лаек. З. Хәкимнең фәлсәфи һәм сатирик прозасы узган гасыр ахырында татар иҗтимагый тәнкыйтен яңа баскычка күтәргән иде. Мәзәкчән ситуацияләрне сатирик максатларда файдалану, башка сатира алымнары авторның сатирик концепциясен тулы килеш кабул итәргә мөмкинлек бирә. «Җыр бәһасе» әсәрендә хикәяче проблеманы алдан ук «мәдәният өлкәсендә чуалып йөреп тамак туйдыручылар, сәнгать әһелләре тротуардан җим чүпләүче күгәрченнәрдән күбрәк» [Хәким, 2014] дип тәгаенли һәм бу күренешнең сәбәбен эзли. Ярлы-кыяфәтсез атаклы композиторга урамда очратып җылы сүзләр әйткәннән соң, мәшһүр шәхес, утыз мең акча сорап, гап-гади тамашачаны йөдәтеп бетерә, шантаж оештыра, ахыр чиктә суд аша илле мең итеп ала. Татарның данлыклы баянчысы Морпый Әүлиятовны (исеменең мәгънәсез, фамилиясе әүлия сүзеннән алынганы сатира алымы) күрә алмас дәрәҗәгә җиткән бу ир, ни гаҗәп, бераз вакыт үтеп, җырын янәдән тыңлаганнан соң, хушланып, үзен, беренче сораганда ук, акча бирмәгәнлегенә гаепле саный башлый. Кешедәге кимсенү, талантлы яки гадәти бер кеше булуга карамастан, аны шул дәрәҗәдә мәгънәсез көн итәргә этәрә, булыр-булмас сәнгать әсәренә мөкиббән китеп, без шушы хәлне үзебез бар итәбез, кебек аңланган автор карашы чишелеш төсендә тәкъдим ителә. Язучының «Наркокурьер» [Хәким, 2014] хикәясендә ярлы Мидхәтнең урлаган ботинкасы эчендә наркотиклар табылу вакыйгасы сөйләнелә. Мидхәт сорау алу барышында ботинканы урлаганлыгын таныярга мәҗбүр була, шулай азат ителә, тегесе дә судан коры чыга. Ботинка хуҗасы соңрак Мидхәткә азат ителү куанычыннан яңа ботинка бүләк итә, Мидхәт исә куркудан аны елгага ташлый. Сатирик бәян дип билгеләнгән «Сәер никрут» [Хәким, 2014] әсәрендә җәмгыятьнең саркастик моделе тудырыла. «Җәмгыятьне идеаль герой белән янәшә куеп бирүгә» [Загидуллина, б. 204] корылган бәяндә, илне саклар өчен, армиягә китәргә теләгән егет – гади җир кешесе – балта остасы психиатрлар, полиция, прокуратура хезмәткәрләре, депутатлар белән очраша. Егет белән булган хәлләрне сурәтләп, автор, субъектив фикерен алга чыгарудан бигрәк, уйланырга урын калдыра. Шул рәвешле, З. Хәкимнең сатирик модуска корылган хикәяләрендә кешеләрдәге гамьсезлек, беркатлылык, курку, кимсенү сыйфатлары фаш ителә.

Сатира остасы Ф. Баттал «Дөньяның асты өскә киләчәк» [Баттал] хикәясендә түбән уйгамәлләрдән көлүгә кешеләрнең барлык уйларын укый һәм белә торган *күзлек* детале ярдәмендә ирешә. Шул рәвешле автор җәмгыятьне басып алган азгынлык, фәхешлекне фаш итә. «Суялар гына...», «Кешеләр шәп – була яшәп» хикәяләрендә гаиләдә ир белән хатын арасындагы сансызлык, кансызлык, көнитештә җинаятьчелекнең гадәти күренешкә әверелә баруы ачы көлү объектлары булып тора.

Сатирик модуска корылган эпик текстлар арасында бәян жанрына нисбәтлеләре дә бар. Д. Заһидуллина 1980 еллардан башлап күп кенә язучылар үз романнарын һәм повестьларын бәян, кыйсса дип атый башладылар дигән карашта тора: «Бәян – хикәяләү, хәбәр итү, аңлату, хикәя яки сөйләп бирү. XIX йөз ахыры-XX йөз башында урта эпик жанр атамасы булып килә» (тәрҗ. безнеке. – *Г. Г.*) [Загидуллина, б. 135]. Әдәби алымнарны төрләндерүнең әсәр жанрын билгеләүгә йогынты ясавы билгеләнеп, аның «прозаның күчеш этабына» хас сыйфат икәнлеге ассызыклана [Загидуллина, б. 135]. Соңгы елларда дөнья күргән Н. Гыйматдинова, А. Әхмәтгалиева, Г. Гыйльманов, Р. Батулла, Ф. Бәйрәмова, Р. Рахман повесть-бәяннәре полифонизм (күптавышлылык), экзистенциаль мотивларга, психологизмның аң агышы алымына мөрәҗәгать итү ягыннан аеруча кызыклы.

Р. Рахманның «Көт син мине» бәяне [Рахман, 2014] сатирик пафосы, проблемалар куелышы белән игътибарны җәлеп итә. Сания-Зәйнулла тарихы ярдәмендә совет җәмгыятенә тәнкыйди бәя бирелә. Автор карашы, бердән, геройлар сөйләме аша белдерелә, икенчедән, Ф. Әмирханча, Т. Миңнуллинча, сатирик кимәлдә тәкъдим ителә. Әсәрдә гөнаһ-җәза мотивы да калкытып куела. Дуңгыз фермасы төзегән Якупны «*яшен сукмый, чир алмый*», ләкин сугышта мәгънәсез үлем белән китеп бара һ. б. Әдибә «Жди меня» шигырен кайма итеп урнаштыру, аның язылу тарихын сөйләү, укучы хәтерендә яши торган мәдәни мәгълүматлар белән ассоциация тудыру алымнары ярдәмендә текстны мәгънәви яктан киңәйтә.

Р. Батулланың «әкият, легенда теле белән язылган» [Загидуллина, б. 201] «Ике җүләр» повестенда [Батулла, 2014] җәмгыятьнең төрле

катламнарына бәя бирү максатыннан, Җүләр Габдулла һәм Җүләр Сирай образлары кулланыла. Вакыйгалар вакытын XX йөзнең 70-80 еллары дип төгәлләштереп, автор бүгенге җәмгыятькә хас гамьсезлек, ясалмалык, наданлык кебек проблемаларны күтәрә. Язучы, авыл җәмгыятендә генә түгел, зыялылар арасында да гамьсезлек җитәрлек дигән фикерне җиткерү өчен, китап укырга ярата торган Сираҗетдинне язучылар даирәсендә тасвирлый. Бу образ эшләнеше белән Т. Миңнуллинның Минһаҗ картын хәтерләтә. Сатирик һәм трагик пафос бер-берсенә керешеп китеп, Җүләр Сирайның үлеменнән бигрәк, авыл халкының Сирай үлгәч әрнүе тетрәндерә. Баксаң, Сирайның җүләр дә, гамьсез дә түгеллеген һәркем белә, кычкырып әйтмәсә дә, таный икән бит. Автор, «җүләрләр» җәмгыятендә сәер тоелган кеше тибын сурәтләү ярдәмендә, укучы хәтерендә яши торган дини-мәдәни мәгълүматлар белән ассоциация тудырып, иҗтимагый проблеманы калкытып куя. Хикәядә Сарташ авылы – сары таш дип бирелгән урын ике гасыр чиге татар прозасындагы «сары йорт» образы белән бәйләнештә укыла.

Бәян жанрындагы аерым әсәрләрдә иҗтимагый проблематика сентименталь пафос һәм экзистенциаль сагыш мотивы аша калку гәүдәләндерелә. Р. Габделхакованың «Соңгы сорау»ында [Габделхакова] акча эшләү, мал туплау, кунак җыю-сыйлау белән мәшгуль ананың балачактан мәхрүм ителгән газизләре Ания белән Илдар мисалында җәмгыятьнең байлар һәм ярлылар катламына бүленгәнлеге; мул тормышта үскән балаларның, өйдә игътибар, ана назы җитмәү аркасында, ялгыш юлга кереп китүләре, азгынлык, наркомания, җинаятьчелек проблемалары ялгызлык, чарасызлык, яшәүдән баш тарту кебек экзистенциаль мотивларга бәйләп күрсәтелә. Эшлексезлек, байлык артыннан куу, җинаятьчелек, гомумән, җәмгыятьнең әхлакый йөзе турында сораулар Н. Гыйматдинованың «Киребеткән», Кәрим Караның «Өч көнлек дөнья», Айдар Зәкиевнең «Уен» бәяНендә күтәрелә.

А.Әхмәтгалиева «Таллыкүлдә былбыл бар» [Әхмәтгалиева] бәянендә күптавышлылык, психологизм алымнарын төрләндерү, шулай ук экзистенциаль мотивларга мөрәҗәгать итү ярдәмендә иҗтимагый проблемаларны алгы планга чыгара. Эшмәкәр Шамил, эчкече Наилә күңелендәге тирәнгә яшерелгән әрнүсызланулар геройларның эчке монологы, татар укучысына таныш каен образына салынган җан авазы – каен монологы ярдәмендә көчәйтелә. Язучы үсмер чакта бер-берсенә ихлас сөюләрен әйтергә дә кыенсынган Шамил-Наиләнең бәхетсезлегендә җәмгыятьне дә гаепли һәм шул рәвешле илдәге иҗтимагый-сәяси барышка аналитик бәя тәкъдим итеЛә. Әсәрдә кешене чарасыз, көчсез ясый торган Үлем, Өметнең өзелүе, Гөнаһ һәм Җәза экзистенциаль мотивлары тәнкыйтьне тагын да тирәнәйтә «...урлашуга, талауга корылган заманда катлаулар арасында барлыкка килгән тирән упкын гади җир халкын көннән-көн үзенә ныграк тарта иде. Бу – куркыныч төпкел иде... Шунысы тагын да куркынычрак: кешеләр ул упкыннан ераграк китәсе, бер-берсенә кул сузып, яктылыкка, кояшка таба атлыйсы урында, ниндидер каһкаһәле ләззәт белән, аяк астында ялтыраган һәрнәрсәне акчага тиңләп, баш иеп артка таба йөгерәләр дә йөгерәләр... Иреннәре дога итеп бер генә теләкне кабатлый: акча, акча, акча. Аллаһы Тәгаләнең каты кисәтүе булганда, кинәт айнып та киткәндәй тоелалар» [Әхмәтгалиева, б. 117]. Бәян экзистенциаль сагыш белән өретелгән, чарасыздан баласын ташлап калдырган Наиләнең, кызы табылганнан соң, яшәүдән баш тартуы, Шамилнең хакыйкатьне белеп сызлануы мифологик мәгънә йөкләнгән акбүз ат, Таллыкүл, былбыл образлары аша көчәйтелә. Бүген авылны коткарып калу юллары бар дигән автор тавышы әби тәрбиясе алган, Наилә фаҗигасе аркасында үз асылына кайткан Шамил образы аша яңгыратыла. Шамил кызына әнисенең якты хисләрен-истәлеген җиткерәчәк, былбылны – илаһи матурлыкны танырга өйрәтәчәк, Алиянең йөрәгендә киңәшчесе – буыннардан калган әхлак кагыйдәләре – акбүз аты булачак.

Н. Гыйматдинованың «Нурулла» [Гыйматдинова, 2014] бәяне проблема куелышы һәм мөрәҗәгать ителгән әдәби алымнары белән үзенчәлекле. Авылдашлары клиник үлем кичергән Нуруллага әүлия дигән кушамат тага. Мәдәни герой образы алга чыгарыла: әүлия-Нурулла, бетүгә йөз тоткан авыл-колхоздагы иманны тергезү өчен, фани дөньяга кайтарыла. Авыл-җәмгыятьне хәрәмнән тыелу, иманга килү генә коткарып кала ала дигән автор карашы әрвахлар тавышы – Киләхмәт бабай сүзе кебек ишеттерелә. Нәсел-буыннар арасында бәйләнеш төш, үлем саташуы алымнары, Чурайбатыр атамасы аша мәгълүм миф белән бәйләү, Әүлия кабере дип бирелгән

урын образын сакральләштерү аша бирелә. Татарстандагы иң бай кешеләрнең берсе дип тасвирланган Минһаҗев образы аша нәселыруны инша язу өчен генә барлау; үзенең дөньяга ник килгәнен аңламыйча, иренең исемен дә кыскартып әйтә торган мыштым Саҗидә образы аша, кем баласы икәнеңне белмичә, ятимә булып йөрү проблемалары үткенлеге белән куела. Нурулланың «Дәфтәргә исем теркәп кенә шәҗәрә ботакларында яфрак бөреләнми ул» [Гыйматдинова, 2014, б. 44] дигән фикере кешеләр тарафыннан эшләнә торган вак, мәгънәсез гамәлләргә тәнкыйди бәя булып яңгырый. Үз туеннан качып киткән, ләкин шул ук вакытта үлем чигенә атлаган сөйгәнен фани дөньяга кайтарган Туйбикә-Нурулла сызыгы романтик яссылыкта бирелә. Д. Заһидуллина, әдибә иҗатын анализлап, аның әсәрләрендә романтик геройларның вазифаларын ачыклый. Язучы реалист Нурулланы олы хисләр, яшерен әрнү-сызланулар ярдәмендә «чистарта», романтик итә. Чөнки Нуруллага йөкләнгән миссияне – авыл һәм җәмгыятьне гөнаһ баткагыннан тартып алуны реалист герой гына башкарып чыга алмаячак. Димәк, әсәрдәге романтик сызык авторның мөнәсәбәтен күрсәтүгә хезмәт итә.

Н. Гыйматдинованың «Үлмәс» бәяне [Гыйматдинова, 2017] сюжет сызыгы ягыннан башка әсәрләре кебек мавыктыргыч та, гади дә. Үлмәс атлы карчыкның кешеләрне дәвалау тарихы кебек сурәтләнгән эчтәлектә автор берничә дин фәлсәфәсен очраштыра. Мәҗүси йолалар белән тәрбияләнгән Үлмәс атлы кыз бала, Заретдинга баргач, ислам динен кабул итә һәм гаиләсен саклап кала алмаса да, йөрәгенә уеп салган Коръән сүзләрен, мәчетне, Аллаһка тугрылыкны Анасы янына кайтканчы җуймый. Әсәрнең башлам һәм бетем өлешләрен Ана йортыннан китү (туган нигез, йорттан ваз кичү) һәм Ана янына әйләнеп кайту (физик үлем) мотивы үзара бәйли. Сюжет сызыгы совет җәмгыяте турындагы мифны җимерүне күздә тотып эшләнгән. Әсәрнең ярдәмче сюжет сызыгын барлыкка китергән Гөлҗиһан (Джиган) тарихы, әдибә әсәрләренә хас булганча, иҗтимагый проблематиканы реалистик планда калку итеп бирүгә, романтик алымнар ярдәмендә тәэсирлелекне көчәйтүгә хезмәт итә. Язучы, дин фәлсәфәсен тәкъдим итүне максат итсә дә, геройлар бирелеше ярдәмендә, аерым алганда, Үлмәс-Гамбәр тарихы белән аның чикләрен уза. Әсәрдә гади кешеләрнең динне аңлаулары, аны чынбарлыкка яраштырулары Үлмәс-Гамбәр тарафыннан инкарь ителә. 90 яшьлек карчык исеменнән үткәрелгән дөньяга караш – татарның буыннардан буыннарга күчкән яшәеш фәлсәфәсе кебек искә төшерелә. Карчык теле белән әйттерелә торган «ачкыч»лар татар укучысының мәдәни хәтерен активлаштыра («Аллаһ мохтаҗ бәндәсен безгә турылаган икән, шуңа чиксез шөкрана кыл!» [Гыйматдинова, 2017, б. 89]; «Кешеләр тарафыннан кылынган зыянга каршы сабыр бул» [Гыйматдинова, 2017, б. 72]. Ләкин нәкъ менә Гамбәр тарафыннан гап-гади яшәеш кануннарының онытылу сәбәбе дә әйттерелә: «Гөнаһым зур: курку күлмәге киеп җәфаланам» [Гыйматдинова, 2017, б. 12].

Үлмәс тарихы – күңелгә тирән кереп оялаган курку хисеннән котылу тарихы да. Ул әсәрне 1960–1980 еллар татар прозасының алтын мирасы белән тоташтыручы үзәк булып тора. Яратып кияүгә барган Үлмәсне зур сынаулар көтә. Иң элек ул исемен алыштыра, ләкин гомере буе бу атыннан өркеп яши. Безнең карашка, автор кешене куркудан үткәннәргә ихтирам коткара, ил-ватанны алыштырган, карашлар үзгәргән очракта да, хәтерне саклау тиеш дигән фикер үткәрә. Әрнү-сызланулар белән тулы тормыш кичергән Үлмәс, үләр алдыннан, берөзлексез Анасына омтыла, төшләнә. Ана – намус, эчке рухи көч, ихтыяр ул. Намусына беркайчан тап төшермәгән карчык нидән курка, ни өчен курка? Нәкъ шушы сызык игътибарны җәлеп итә дә инде. Ул аңа назлы хатын, акыллы-зирәк таяныч була алмый. Мөмкин идеме соң? Карчыкның ире, улы Рәшиткә бәйле үкенүләре аша автор фикере җиткерелә. Бер яктан, гаярь, икенче яктан башкалардан аерылыбрак торган Гамбәр эчтән көя, туры юл тапмый. Кешеләрнең тәнен дәвалый, аларга ышанычөмет сала, әмма үз тормышына кагылышлы гап-гади сорауларга аның җавабы юк. Гөлҗиһанның исемен алыштырырга мәҗбүр итүе дә – курку нәтиҗәсе. Абага – символик деталь («ул яшеренеп кенә төнлә чәчәк ата» [Гыйматдинова, 2017, б. 42]).

Үлмәс тарихы – яшеренеп чәчәк атучы гөл тарихы ул. Акъәби-Бибинурлар дәвамчысы, дала кызы, бөтен яшәешен ихластан игелек кылуга багышлаган Үлмәс атлы карчыкның куркуы, Сәмигулла кызы Гөлҗиһанны коткаргач, явыз күршесен кызы белән очраштыргач, үз оныгын аның белән кавыштыргач, кичерергә өйрәнгәч бетә (Сәмигулла, Мирхәйдәрләр сызыгы) (әби ак киндер күлмәген киеп, ак

яулыгын бәйли). Ул да гүя бакыйлыкка күчми, татарның тыныч-сабыр, бик күпне үткәрә белә торган зирәк акылын үз итә. Күренгәнчә, Н. Гыйматдинованың 2017 елда дөнья күргән «Үлмәс» әсәрендә 1965 елны иҗат ителгән Акъәби тарихы яңадан «укыла», сурәтләнә. Язучы әсәрендә элгәрге традицияләр дәвам ителеп кенә калмый, ә алар яңа социаль һәм мәдәни шартларда яңартыла да.

Факил Сафинның «Тулган ай» [Сафин] повесте кешеләрнең вәхшилеге турындагы фикерне шартлы-метафорик кимәлдә җиткерү ягыннан әһәмиятле. Әдип Тулганай кушаматлы эт образын кешеләрнең гамьсезлеген, кансызлыгын бәяләү өчен куллана. *Тулган ай* детале исә яшәеш асылы турындагы фикерләрне фәлсәфи гомумиләштерә. Кеше фаҗигасен сентименталь төгәллектә бирү җәһәтеннән Ринат Камалның «Таня-Таңсылу», К. Булатованың «Яшел яфрак – яшәү төсе» бәяннәрен, Сәмига Сәүбәнованың «Әниләр шундый инде алар» хикәясен аерып куярга мөмкин булыр иде. Шул рәвешле, бүгенге прозадагы повестьта әдәби алымнарны төрләндерү, авангардка борылу жанрлар үзгәрешенә дә алып килә.

XXI гасыр дөнья әдәбиятында роман иң зур үзгәрешләр кичергән жанрлардан санала. Соңгы еллардагы милли прозада роман жанрының сыйфат үзгәреше ягыннан алга китеше сизелә. Хәзерге татар прозасында күпсанлы зур күләмле эпик текстлардан тема яңалыгы, сюжет структурасы һәм әдәби алымнар байлыгы белән аерылып торган романнар рәтенә З. Хәкимнең «Легионер», З. Хөсниярның «Гарасат», В. Имамовның «Карабәк», Ф. Бәйрәмованың «Һиҗрәт», М. Әмирхановның «Тәхетсез патша» һ. б. кертергә мөмкин.

Сугыш батырларына дан җырлаган, М. Җәлил образының әдәби укылышын күп тапкырлар тәкъдим иткән татар прозасының хәзерге чорында Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасын сурәтләгән роман дөнья күрде. Икенче Бөтендөнья сугышы елларында Өченче рейхның төрки-мөселман халыклары белән сәяси һәм сугышчан хезмәттәшлек урнаштыру омтылышы тарихчы галим И. Гыйләҗев тарафыннан тирән өйрәнелгән [Гилязов]. Фәнни хезмәт беренче тапкыр басылып чыкканнан соң, дистә ел үтүгә, әлеге тема З. Хәкимнең драма һәм романында әдәби чагылыш тапты [Хәким, 2009]. Язучының «Легионер» романында милли яшәеш моделе тергезелә. Автор татар тормышының борынгыдан үзгәрми килгән рәвешен Кызылъяр авылы сурәтенә салып бәяли. Романның төп сюжет сызыгында вакыйгалар вакыты тарихи билгеләнеш ала: 1941 елның июнь аенда башланган вакыйгалар 2005 елда төгәлләнә. Шәхси сюжет сызыгындагы Яббар-Әнсар каршылыгы иҗтимагый сызыкта үзенчәлекле борылыш ала. Фатыйманы бүлә алмаган егетләргә, мәсьәләне хәл итүгә, Сәет булыша, аннары тормыш сөйгән ярларны үзе аралый. Тексттагы Сәет образы исә Нәгыймнең дәвамчысы, гадел, олпат, киңәшче буларак кабул ителә. Яббар теле белән автор Сәетнең әтисен кабатларга тиешлеген һәрвакыт искәртеп тора. Сюжет сызыгында әсирлектән, Себердән исән-сау әйләнеп кайткан Яббарны иң беренче булып гаепләгән кешеләрнең авылдашлары булу трагик пафосны көчәйтә, хыянәт проблемасын иҗтимагый яссылыктан гомумкешелек яссылыгына күчерә. Әсәрдә Нәгыймнең Яббарга «нәселгә мәңге юылмаслык тап төште» дигән карашының үзгәрү тарихы сөйләнә. Нык ихтыярлы, нечкә күңелле, гадел, якты омтылышлы егет авылдашлары, туганнары хыянәте алдында югалып кала, үзенә кул салырга уйлый, ләкин ныклыгын җуймый. З. Хәкимнең Яббары татар кешесенең гасырлар дәвамында уелган мәгълүмат-кануннарын, буыннардан килгән ныклы нигезен – гармониягә омтылышын, юлын күзәтеп торырга, бәяләргә тиешле символик мәгънәле образ буларак бәяләнә. Яббарның оныгы милли яшәеш турындагы хакыйкатьне җиткерүче итеп тәкъдим ителә. Татар кешесе, үз асылын югалтмас өчен, хәтерен-байлыгын сакларга, илаһига омтылышын – горурлыгын җуймаска тиеш, ди З. Хәким.

Яңа, постмодернистик роман заман сурәтен тергезү һәм бәяләү өчен, моңа кадәр сүз сәнгатендә билгеле булмаган мөмкинлекләр ача. Д. Заһидуллина З. Хөсниярның «Гарасат» романын [Хөснияр, 2014] «чор әдәбияты фонында үз урынын алачак постмодернизмның алым-формалары белән баетылган яңа татар романы» буларак бәяли, әсәрдә күпмәгънәле, ассоциатив, интеллектуаль романга хас булганча, «сюжеттан зуррак мөстәкыйль катламнар» (тәрҗ. безнеке. – *Г. Г.*) [Загидуллина, б. 228] урын ала, дип шәрехли.

Ф. Бәйрәмованың «Һиҗрәт» тарихи романы Мәхмүт Галәү әсәрләре традицияләрен яңарта. Романның тетрәндергеч сюжеты, экзистенциаль әрнүләр белән сугарылган әчке көе, укучы игътибарын тотып, җыеп тора. Әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр авторның

иманга тугрылык турындагы карашы үткәреләә. Биредә татар халкы тарихы, дин тарихы белән тыгыз үрелеп, гаҗәеп көчле яңгыраш ала. Публицистик катлам романдагы әрнү-сызланулар сызыгын авторныкы итеп кабул итәргә мөмкинлек бирә.

Тарихи прозада, мифлаштыру алымына мөрәҗәгать итеп, романтик яссылыкта идеаль герой сурәте тудырыла. В. Имамовның «Карабәк» [Имамов] романы XIV гасырның икенче яртысында булып үткән тарихи вакыйгаларны тасвир итә. Бу әсәрнең бүгенге мәдәни-иҗтимагый барыштагы урынын билгеләп, И. Заһидуллин болай дип яза: «Милли идеология шанлы тарихи темаларга мохтаҗ, бигрәк тә милли күтәрелеш һәм кризис вакытларында тарихи әсәрләргә ихтыяҗ арта, тарихи әсәрләр татар укучысының тарихи хәтерен яңартуда мөһим роль уйный» [Заһидуллин]. Романда бүгенге реалистик прозадагы милли каһаман образын камил инсан концепциясенә туры китереп тәкъдим итү тенденциясе күренә. Габдулла (Карабәк) – татар кешесенең аң төпкелендәге гаярь, ихлас, көчле, көрәшче сыйфатларының җыелма төстә гәүдәләнеше ул. Шул рәвешле, тарихны тергезү белән беррәттән, әлеге роман укучы хәтерендә, аң төпкелендә яши торган мәгълүматларны файдалануга да йөз тота. Шулай итеп, реалистик романда интеллектуаль әдәбиятка хас алымнарга максатчан мөрәҗәгать ителә.

Хәзерге татар прозасына жанрлык хасиятләре, әдәби алымнар яссылыгында күзәтү ясаганнан соң, аны тагын да камилләштерү юнәлешендә түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Язучылар әдәби концепция максатында аллегорик, шартлы-ассоциатив, метофорик сурәтне көчәйтсәләр, эстетик яктан камиллеккә, тәэсирлерәккә ирешү мөмкинлеге артыр иде. Проза әсәрләрендә кеше фаҗигасен сурәтләү, тормышны хисләр тарихы итеп күрсәтү барышында укучы хәтерендә яши торган мәдәни мәгълүматларны файдалану укучының акыл эшчәнлеген активлаштыруга, аны да иҗат эшенә тартуга юл ачачак.

Соңгы еллар татар прозасында, хикәя, повесть, бәян, роман жанрлары әдәби алымнарны төрләндерү, традицион алымнарны куллану белән беррәттән, авангард алымнарга мөрәҗәгать итү ягыннан сыйфат үзгәрешләре кичерә. Шул сәбәпле милли прозада күчеш чорына хас аерым билгеләр дә күзәтелә. Повесть жанрының бәян дип тәкъдим ителүе, хикәя жанрының авангард юнәлешкә тартылуы, роман жанрының, тарихи темаларны үз итеп, интеллектуаль әдәбиятка хас алымнар белән баюы хәзерге татар прозасын жанрлык хасияләре яссылыгында бәяләүнең әһәмиятен дәлилли.

**Әдәбият**


*Әбударова Л.* Газап // Идел. 2017. № 3. Б. 53–62.

*Әдһәм Г.* Зәңгәр кашлы көмеш алка // Казан утлары. 2014. № 5. Б. 5–58.

*Әхмәтгалиева А.* Таллыкүлдә былбыл бар: повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 285 б.

*Баттал Ф.* Аз-азлап кына: юмористик һәм сатирик әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 381 б.

*Батулла Р.* Ике җүләр // Казан утлары. 2014. № 4. Б. 64–89.

*Габделхакова Р.* Соңгы сорау // Казан утлары. 2014. № 3. Б. 11–14.

*Гайнуллина Г. Р.* Зиннур Хөсниярның «Кичү» хикәясендә авангард алымнар // Татарское языкознание в контексте Евразийской гуманитарной науки: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 1–4 ноября 2016 г.) / под ред. Р. Р. Замалетдинова, Г. Р. Галиуллиной. Казань: изд-во Казан. ун.-та, 2016. С. 101–104.

*Галиуллин Р.* Җиһан // Казан утлары. 2014. № 12. Б. 104–108.

*Гыймадова Г.* Пәрәвез җебе яки кыз-әби кыйссасы // Казан утлары. 2014. № 3. Б. 52–61.

*Гыйматдинова Н.* Нурулла // Казан утлары. 2014. № 7. Б. 12–101.

*Гыйматдинова Н.* Үлмәс // Казан утлары. 2017. № 9. Б. 3–101.

*Заһидуллина Д. Ф.* Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.

*Иксанова И. В.* Балан чәчәге: повесть, хикәяләр, телевизион фильм һәм сценарий, эссе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 189 б.

*Имамов В.* Карабәк // Казан утлары. 2017. № 5. Б. 11–77; № 6. Б. 7–79.

*Кәбиров М.* Китап: роман, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 461 б.

*Рахман Р.* Бәйрәм // Казан утлары. 2017. № 4. Б. 93–107.

*Рахман Р.* Көт син мине // Казан утлары. 2014. № 12. Б. 76–103.

*Сафин Ф.* Тулган ай // Казан утлары. 2014. №4. Б. 110-118.

Хак тарихны кайтару юлында // Казан утлары. 2017. № 10. Б. 120–136.

*Хәким З.* Җыр бәһасе // Казан утлары. 2014. № 11. Б. 24–58.

*Хәким З.* Легионер: роман, повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 367 б.

*Хәким З.* Наркокурьер // Казан утлары. 2014. № 10. Б. 22–64.

*Хәким З.* Сәер никрут // Казан утлары. 2014. № 11. Б. 13–53.

*Хөснияр З.* Гарасат: роман-дилогия. Казан: «Хузур» нәшрият йорты, 2014. 520 б.

*Хөснияр З.* Кичү: хикәяләр, повестьлар, роман-диология. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 575 б.

*Якупова С.* Хикәяләр // Казан утлары. 2014. № 3. Б. 55–100.

*Гилязов И. А.* Легион «Идель-Урал». Москва: Вече, 2009. 299 с.

*Загидуллина Д. Ф.* Современная татарская проза (1986–2016 г.г.): основные тенденции историко-литературного процесса. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 246 с.

*Iusupov A. V., Gilazov T. Sh.* (2016). The Critic Jahmal Validi in the Context of Literary, Theoretical and Philosophical Searches of the Beginning of the XX Century Literature. Journal of Language and Literature, ISSN: 2078– 0303, Vol. 7. No. 2. May, pp. 344–347.

# СОВРЕМЕННАЯ ТАТАРСКАЯ ПРОЗА: ЖАНРОВОЕ СВОЕОБРАЗИЕ, ХУДОЖЕСТВЕННЫЕ ПРИЕМЫ

**Гульфия Расилевна Гайнуллина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
gulfiarasilevna@mail.ru.

В статье на основе анализа ряда произведений выявляется жанровое своеобразие современной татарской прозы, богатство художественных средств. Определены ключевые тенденции в прозе последних лет. Констатируется, что рассказ как жанр переживает обновление и рост, особенно в плане философских обобщений, использовании традиционных средств психологизма, эмоциональной тональности, символов. В рассказах последних лет общественно-социальные проблемы переплетаются с философскими, антропологическими. Рассказы А. Ахметгалиевой отличает приверженность к национальным традициям, ориентация на восточную эстетику, стремление к лиризации прозы. В рассказах Р. Галиуллина, Г.Адхама, Р. Рахман, И. Иксановой, Л. Ибрагимовой и др. доминирует экзистенциальная проблематика, которая находит воплощение через разнообразие поэтических приемов. М. Кабиров, З. Хуснияр, Л. Абударова создают рассказы, которые относятся к авангардной прозе. В жанре повести доминирует сатирическая образность (З. Хаким, Р. Батулла, Ф. Баттал, Р. Рахман и др.). В жанре бэян экзистенциальные мотивы переплетаются с идеей возвращения к истокам, возрождением патриархальных нравственных ценностей. (А. Ахметгалиева, Н. Гыйматдинова и др.). Зримые изменения в XXI веке переживает жанр романа, особенно в плане национального своеобразия. Выделяются в плане новаторства тематики, структуры сюжета и богатства поэтических средств романы З. Хакима, З. Хуснияра, Ф. Байрамовой, В. Имамова.

В статье систематизированы работы по современной татарской прозе (Д. Загидуллина, М. Хабутдинова, Л. Давлетшина, А. Шамсутова и др.).

**Ключевые слова**: современная татарская проза, рассказ, повесть, бэян, роман, экзистенциальные мотивы, психологизм, символы.